КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2022 ел, 6 апрель

г.Казань

№ 322

«Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Терлекчелектә нәсел эше буенча баш дәүләт авыл хуҗалыгы идарәсе» дәүләт казна учреждениесен бетерү турында

Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Терлекчелектә нәсел эше буенча баш дәүләт авыл хуҗалыгы идарәсе» дәүләт казна учреждениесен (алга таба - Учреждение) бетерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына:

эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көн эчендә:

Учреждениенең ликвидация комиссиясе составын расларга;

Учреждениене бетерү тәртибен һәм срокларын Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә билгеләргә;

Учреждениене бетерү турында карар кабул ителгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Учреждениенең бетерү процессында булуы турындагы мәгълүматларны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен терки торган органга бирергә;

эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән күчемсез мөлкәтен алга таба файдалану турындагы тәкъдимнәрне, шулай ук күчемсез мөлкәт объектларына техник документацияне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә Учреждениене бетерү нәтиҗәсендә азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә, шулай ук Учреждениене бетерү буенча законнарда каралган башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. Учреждение йөкләмәләре буенча, шул исәптән суд карарларын үтәү нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөкләмәләр буенча җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы итеп Учреждениене гамәлгә куючының вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тәкъдим иткән исемлек нигезендә, элек Учреждениегә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен календарь көннәрдә исәпләнә торган 60 көн эчендә законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшыруны тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин